ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^{1}$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$10^{1}$ статья. **Мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калуны, алардан файдалануны, аларны популярлаштыруны, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне), ачыкланган мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклауны тәэмин итәләр.»;

2) $10^{2}$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^{1}$ статья өстәргә:
«$17^{1}$ статья. **Мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган исемлектәге халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калуны һәм популярлаштыруны оештыруда, шул исәптән тиешле чараларны финанслауда, шулай ук дәүләт саклавы вәкаләтләре мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) дәүләт саклавы чараларын финанслашуда катнашырга;

федераль дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан китапханәләрнең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыруда катнашырга;

Россия Федерациясе Музей фондының составына федераль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган дәүләт өлешен һәм Россия Федерациясе Музей фондының составына муниципаль милектәге музей предметлары һәм музей коллекцияләре керә торган дәүләтнеке булмаган өлешен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан музейлар белән үзара эшчәнлек аша саклап калуда һәм тулыландыруда катнашырга;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль милектәге һәм хуҗалык алып бару йә оператив идарә итү хокукында дәүләт циркларына беркетелгән мөлкәтне реконструкцияләү, шул исәптән реставрация элементларын да кертеп, яңадан техник җиһазландыру һәм капиталь ремонтлау чараларын финанслауда катнашырга.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 4 өлешенә (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль яисә муниципаль милектәге мәдәни мирас объектларын саклап калуны һәм популярлаштыруны оештыруда, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тиешле чараларны финанслауда, шулай ук дәүләт саклавы вәкаләтләре Татарстан Республикасы дәүләт

хакимияте органнарына тапшырылган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы чараларын финанслашуда катнашырга хокуклы.».

**3 статья**

«Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары федераль дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан китапханәләрнең китапханә фондларын туплауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыруда катнашырга хокуклы.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 20 июнь
№ 54-ТРЗ